| Республика Татарстан | Татарстан Республикасы |
| --- | --- |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| ул. Советская, д. 47, с. Муртыш-Тамак 423358 Телефон: 4-52-05 | Совет урамы, 47 йорт, Мортыштамак авылы, 423358 Телефон: 4- 52-05 |

КАРАР
«04 »июнь, 2017ел. № 8

2014 елның 5 маендагы 8 номерлы Мортыштамак авыл җирлеге советы карары белән расланган Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль хезмәт турында нигезләмәне «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 1 маендагы 90-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Мортыштамак авыл җирлеге карар итте

1. 2014 елның 5 маендагы 8 нче карары белән расланган Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» МБ муниципаль хезмәте турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 бүлекнең 5.4.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ел саен төп түләүле отпуск муниципаль хезмәткәргә 30 календарь көн дәвамлылыгы белән бирелә».

2) 5 бүлекнең 5.5.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ел саен өстәмә түләүле отпусклар муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән (10 календарь көннән дә артык булмаган дәвамлылыгы) өчен, шулай ук федераль законнарда һәм Россия Федерациясе субъекты законнарында каралган очракларда бирелә. Нормалаштырылмаган хезмәт көне билгеләнгән муниципаль хезмәткәргә нормалаштырылмаган хезмәт көне дәвамлылыгы өч календарь көнгә тигез еллык өстәмә түләүле отпуск бирелә».

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман районы
Мортыштамак авыл
җирлеге башлыгы М.Н.Әхмәтгәрәев